**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Югары Шепкә авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**№ 159** **20 май 2020 ел**

**2019 елда Зәй муниципаль районының**
**Югары Шепкә авыл җирлеге бюджеты**
**үтәлеше турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2019 ел өчен Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисапны керемнәр буенча 10168,6 мең сум, чыгымнар буенча10038,6 мең сум, керемнәрне чыгымнардан 130,0 мең сумга арттырып, һәм түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

1.1. 2019 ел өчен бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча әлеге карарга 1нче кушымта нигезендә;

1.2. 2019 ел өчен бюджет керемнәре буенча әлеге карарга 2нче кушымта нигезендә;

1.3. 2019 елга бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 4нче кушымта, тармак структурасы буенча бюджет чыгымнарын 3нче кушымта нигезендә расларга.

2.Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар билгеләнгән тәртиптә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе урынбасары** **М.Г.Низамиева**